ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

Постановление                                        Карар

2019 елның 25 нче феврале        Чистай шәһәре        № ___87______

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
территориясендә туберкулезны,
ВИЧ - инфекцияне, В һәм С гепатитларын
һәм женси юл белән тапшырыла
торган инфекцияләрне профилактикалау,
таратуны кисәтү буенча ведомствоара
комиссия төзү турында

Туберкулезны, ВИЧ-инфекцияне, В һәм С гепатитларын һәм женси юл белән тапшырыла торган инфекцияләрне профилактикалау, таратуны кисәтү эшен камилләштерү, шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы территориясендә куркыныч авырулар белән көрәш мәсьәләләре буенча кызыксынучы хезмәтләр һәм оешмаларның эшен координацияләү максатларында, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты,

**Карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы территориясендә халык арасында туберкулез, ВИЧ-инфекция, В һәм С вируслы гепатитлары һәм ИППП таралуны профилактикалау, кисәтү буенча ведомствоара комиссия төзергә.
2. Комиссия Нигезләмәсен һәм составын расларга ( № 1, 2 нче кушымталар).
3. Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының “Туберкулезны, ВИЧ-инфекцияне, ИППНЫ профилактикалау, таратуны кисәтү буенча ведомствоара комиссия төзү турында”гы 2017 елның 20 декабрендәге 989 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Г. Ю. Задворнованы йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе                                        Э.Р. Хәсәнов

Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының
__________елгы____номерлы карарына
1 нче Кушымта

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы территориясендә халык арасында туберкулез, ВИЧ-инфекция, В һәм С вируслы гепатитлары һәм ИППП таралуны профилактикалау, кисәтү буенча ведомствоара комиссиясе турында
Нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы территориясендә ведомствоара комиссия (алга таба Комиссия дип атала) сәламәтлек саклау оешмалары белән туберкулез, ВИЧ-йогышы, В һәм С инфекцияләре гепатитлары, ИПП белән көрәш мәсьәләләре буенча, халык арасында аларны киметүне һәм таратуны тәэмин итү өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл итү максатларында оешты.

1.2. Комиссия эшчәнлегенең хокукый нигезен Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясе Президенты һәм Татарстан Республикасы Президенты указлары һәм боерыклары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әлеге Нигезләмә тәшкил итә.

1.3. Комиссиянең персональ составы һәм нигезләмә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан раслана.

## II. Комиссиянең төп бурычлары.

2.1. Ведомствоара комиссиянең төп бурычы-туберкулезны, ВИЧ-инфекцияне, В һәм С вируслы гепатитларын, ИППП, профилактик һәм эпидемиягә каршы чараларны үткәргәндә хезмәтләр һәм оешмаларның үзара бәйләнешенә бәйле мәсьәләләр буенча карарлар әзерләү, куркыныч инфекцияләр таралуга эпидемиологик күзәтчелекне камилләштерү.

2.2. Ведомствоара комиссия дәүләт һәм ведомство санитар - эпидемиологик күзәтчелекне гамәлгә ашыру, халыкның, шулай ук декретацияләнгән контингентларга һәм риск төркемнәренә караган затларның санитар кагыйдәләрен үтәүне тикшереп тору, профилактик медицина тикшерүләрен оештыру һәм үткәрү буенча чаралар оештыру мәсьәләләрен карый;

2.3. Үз утырышларында Чистай районы территориясендә урнашкан милек рәвешләренә бәйсез рәвештә учреждение, оешма җитәкчеләре һәм башка юридик затлар турында, туберкулез, ВИЧ - инфекциягә, В һәм С гепатитларына һәм ИППП каршы көрәш мәсьәләләре буенча алар тарафыннан күрелә торган чаралар турында мәгълүматны тыңлый;

2.4. Йогышлы авыруларны профилактикалау өлкәсендә үткәрелгән профилактик һәм эпидемиягә каршы чараларның нәтиҗәлелеген карый;

2.5. Бу инфекцияләрнең таралуын кисәтү буенча эшнең уңай тәҗрибәсен өйрәнә, аны “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлеге муниципаль хакимият органнары эшчәнлегенә кертү буенча тәкъдимнәр әзерли.

III. Комиссия эшчәнлеге тәртибе.

3.1 Комиссия рәисе комиссия эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә. Ул булмаганда комиссия рәисе урынбасары җитәкчелек итә.

3.2. Муниципаль хакимият органнарына карауга норматив хокукый актлар тәкъдимнәрен һәм проектларын тәкъдим итә. Комиссиягә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен җаваплы.

3.3. Комиссия үз эшчәнлеген утырышта раслана торган эш планы нигезендә башкара.

3.4. Комиссия утырышлары комиссия рәисе, яисә аның кушуы буенча комиссия рәисе урынбасары тарафыннан мөһим булганда, кварталга кимендә бер тапкыр уздырыла. Комиссия утырышына, күтәрелүче мәсьәләләргә карап, төрле хезмәт һәм оешма вәкилләре чакырылырга мөмкин.

3.5. Комиссия утырышлар үткәрергә һәм аның әгъзаларының кимендә өчтән икесе булган очракта карарлар кабул итәргә хокуклы. Комиссия әгъзалары утырышта карала торган мәсьәләләр турында фикер алышканда тигез хокукларга ия.

3.6. Комиссия карарлары комиссия утырышында катнашкан әгъзаларның күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә. Тавышлар тигез булганда, Комиссия рәисе яки аның урынбасары (рәис булмаганда) хәлиткеч тавышка ия. Утырышта булмаган очракта комиссия әгъзасы каралучы мәсьәләләр буенча үз фикерләрен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы. Әлеге фикер комиссия утырышында каралганда исәпкә алына һәм беркетмәгә теркәлә.

3.7. Комиссиянең эш регламенты комиссия рәисе яисә аның урынбасары тарафыннан раслана.

3.8. Комиссия эшчәнлеген матди-техник яктан тәэмин итүне Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты Аппараты башкара.

3.9. Кварталга бер тапкыр системалы рәвештә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә Комиссия эшчәнлеге нәтиҗәләре турында хәбәр итә.

Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының
_________елгы____номерлы карарына
2 нче Кушымта

**Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы территориясендә халык арасында туберкулез, ВИЧ-инфекция, В һәм С вируслы гепатитлары һәм ИППП討 таралуны профилактикалау, кисәтү буенча ведомствоара комиссиясе**
**Составы**

Комиссия рәисе:
Г.Ю. Задворнова - Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары;

Комиссия рәисе урынбасары:
Р.Р. Мостафин – “Чистай РҮХ” ДАССОның баш табибы (килешү буенча);

Комиссия сәркатибе:
Р.Г. Хәсәнҗанова – “Чистай РҮХ” ДАССОның табиб-эпидемиологыК
Комиссия әгъзалары:
- Ф.С. Хәйруллина – “Роспотребнадзор”ның Татарстан Республикасы буенча Чистай,Спас,Алексеевск, Яңа Чишмә районнарында территориаль идарәсе башлыгы (килешү буенча);

- Э.И.Гыйлметдинова –“ ФБУЗ «ЦГ һәм Э Чистай, Спасс районнарында» баш табибы вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча);

- Р.М. Нуруллин - "РККВД" ДАССОның Чистай КВД филиалының баш табибы»(килешү буенча);

- Н.Н. Дәүләтханов – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең Алексеевск территориаль бүлеге җитәкчесе (килешү буенча);

- З.З. Шәрипов - «Чистай район дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ башлыгы-Чистай районының Баш ветеринария табибы (килешү буенча);

- Г.К. Шарафутдинова - заместитель начальника ОУУП ОМВД России по Чистопольскому району (килешү буенча);

- Лидия Анатольевна Волкова– Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре буенча бүлек башлыгы;

- О.В. Добронравова – югары белем бирү учреждениесе В.Г.Тимирясов исемендәге “Казан инновацион университеты” Чистай филиалы директоры (килешү буенча);

- В.С. Толоконников - Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының спорт бүлеге начальнигы;

- Р.Н. Хөснуллин – Чистай муниципаль районы Советының иҗтимагый оешмалар, ММЧ һәм милләтара мөнәсәбәтләр белән эшләү бүлеге башлыгы (килешү буенча);

- Г.Р. Каюмова – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Чистай муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча);

- Г.В. Гатауллина – Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе җитәкчесенең тәрбия эшләре буенча урынбасары (килешү буенча);

- Н.З. Мостафин – «Татарстан Республикасында (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге» ФБССОның Чистай, Спас районнары филиалы эпидемиология табибы (килешү буенча);

- С.К. Проничева – Чистай муниципаль районы Иҗтимагый советы рәисе (килешү буенча);

- Мөхәммәт хәзрәт Кыямов - Чистай шәһәре һәм Чистай районы Имам-мөхтәсибе (килешү буенча);

- Иерей Николай Андриевский – ключарь Никольского собора (килешү буенча).